БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«22» 02 2024 ел № 90

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибен һәм срокларын раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына (дәүләт органнарына), территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондларының идарә органнарына, җирле үзидарә органнарына, җирле администрация органнарына бюджет керемнәренең баш администраторы вәкаләтләрен беркетүгә һәм Россия Федерациясе субъекты бюджеты, территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслауга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2021 елның 16 сентябрендәге 1569 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибен һәм срокларын раслау турында» 2021 елның 30 декабрендәге 1345 номерлы карары нигезендә Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертүнең кушымтада бирелгән тәртибен һәм срокларын расларга.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2024 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач муниципаль районының финанс-бюджет палатасы һәм Балтач муниципаль районының мөлкәти һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисләренә йөкләргә.

Җитәкче А. Ф. Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
карарына кушымта

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибе һәм сроклары

Әлеге Тәртип Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына (дәүләт органнары), территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондларының идарә органнарына, җирле үзидарә органнарына, җирле администрация органнарына бюджет керемнәренең баш администраторы вәкаләтләрен беркетүгә һәм Россия Федерациясе субъекты бюджеты, территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты, җирле бюджет керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслауга карата Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына (дәүләт органнарына), территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондларының идарә органнарына, җирле үзидарә органнарына, җирле администрация органнарына бюджет керемнәренең баш администраторы вәкаләтләрен беркетүгә һәм Россия Федерациясе субъекты бюджеты, территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслауга гомуми таләпләрне раслау турында» 2021 елның 16 сентябрендәге 1569 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибен һәм срокларын раслау турында» 2021 елның 30 декабрендәге 1345 номерлы карары белән расланган гомуми таләпләрнең 10 нчы пункты нигезендә эшләнгән һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү механизмын һәм срокларын билгели (алга таба - исемлек, баш администратор).

Исемлеккә, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджеты керемнәре классификациясенең баш администраторларына беркетелгән кодлар составына үзгәрешләр Балтач муниципаль районы финанс-бюджет палатасының боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслау турында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертмичә, төп

администраторлар составы һәм (яисә) функцияләре үзгәргән очракта, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджеты керемнәре классификациясен билгеләү һәм бирү принципларын үзгәртү нигезендә, тиешле елга кертелә.